

2014 елның 3 нче декабрендә илебездә беренче тапкыр «Билгесез солдат Коне» билгеләп үтелде.

Россия Дәүләт Советы депутатлары тәкъдиме белән тарихи дата итеп билгеләнгән «Билгесез солдат Коне» - яу кырларында башларын салып, исемнәре ачыкланмый калган сугышчыларны - Ватаныбыз улларын искә алу, аларнын батырлыгы алдында баш иеп, хәтерләрне янарту ул. 1966 елның 3 декабрендә, Мәскәү астында немец гаскәрләрен тар-мар итүгә 25 ел тулу унаеннан, Александровский бакчасында тантаналы рәвештә билгесез солдат коле жирләнә. Аны Зеленоград шәһәренә керү юлында урнашкан туганнар каберлегеннән күчергәннәр. 1967 елда Александровский бакчасында мәнгелек ут кабызыла һәм «Штыки» мемориаль комплексы ачыла.

Боек Ватан сугышынын илгә күпме югалтулар алып килүе турында ачынып сойлибез. Күпме якташларыбыз яу кырыннан кайта алмаган, ә күпмеләре әле хәзер дә хәбәрсез югалганнар исемлегендә йори. Мәнгелек ут һәм һәйкәл янына чәчәкләр Рузаевка районы Татар Пешлә авылы администрациясе белән Мәдәният йорты вәкилләре, Татар Пешлә урта мәктәбе директоры Флора Әхмәтжан кызы Шамонова житәкчелегендә 5 (класс житәкчесе Сания Спартак кызы Саляева), 10 (класс житәкчесе Светлана Федоровна Медведева), 11 (класс житәкчесе Елена Сергеевна Рахмукова) сыйныф укучылары сугышта башларын салган геройларны бер минут тынлык белән искә алганнар, мәнгелек ут янына гвоздикалар салганнар. Шуннан сон барлык класс житәкчеләре укучыларына Билгесез солдат батырлыгы турында, презентацияләр кулланып, чаралар үткәргәннәр. Сания Спартак кызыннан нәрсә турында сойләден дип сорагач:



